КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 30 декабрь г.Казань № 1245

«Тулай торакларда торак урыннары белән тәэмин итү» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында

Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең сыйфатын яхшырту, халыкның барлык катламнары өчен аларның файдалана алырлык булуын тәэмин итү һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүче оешмаларга карата таләпләрне стандартлаштыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән «Тулай торакларда торак урыннары белән тәэмин итү» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасының һөнәр белеме бирү оешмалары, югары белем бирүче мәгариф оешмалары тулай торакларында яшәүче укучыларга хуҗалык-көнкүреш хезмәте күрсәтүне тәэмин итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2013 ел, 19 август, 575 нче;

«Башлангыч, урта һәм югары һөнәр белеме бирү учреждениеләренең тулай торакларында яшәүче укучыларга хуҗалык-көнкүреш хезмәте күрсәтүне тәэмин итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2013 ел, 19 август, 575 нче карары белән расланган Башлангыч, урта һәм югары һөнәр белеме бирү учреждениеләренең тулай торакларында яшәүче укучыларга хуҗалык-көнкүреш хезмәте күрсәтүне тәэмин итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 ел, 21 гыйнвар, 26 нчы;

«Башлангыч, урта һәм югары һөнәр белеме бирү учреждениеләренең тулай

торакларында яшәүче укучыларга хуҗалык-көнкүреш хезмәте күрсәтүне тәэмин итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2013 ел, 19 август, 575 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 ел, 12 ноябрь, 860 нчы.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин